күп профильле
181 нче мәктәп

# Күкнең җиденче катында

## Мәктәп яңалыклары...

5 нче чыгарылыш

4 нче февраль

**БУ САНДА:**


| | |
|---|---|
| Бәйрәм белән! | 1 |
| Ленинград камалышын өзүгә 75 ел! | 2 |
| Яңалыклар | 3 |
| Сак булыгыз, грипп! | 4 |






**Дус күршеләр булып яшик гөрләп,**
**Охшаш безнең телләр, гадәтләр.**
**Тынычлык һәм дуслык чәчәк атсын,**
**Уртак булсын матур теләкләр.**

**Бердәмлекнең көче океан,**
**Океаннан да хәтта көчлерәк.**
**Без күтәргән дуслык байрагы**
**Гасырларга барыр җилфердәп.**

# Ленинград камалышын өзүгә 75 ел



27 гыйнварда Ленинград камалышын өзүгә 75 ел тулды. Ил тарихына җуелмас хәрефләр белән язылган бу 900 көн һәм төн барлык заманнарда да һәр буын өчен чиксез батырлык, чыдамлылык һәм корычтай ныклы рух билгесе дә ул.

Сабыйлар тыныч йокласын,

Кан түгелмәсен!
Безнең аналар яңадан
Хәсрәт күрмәсен! Теләмибез сугышны без!
Без тынычлык телибез!
Безнең якты тормышыбыз
Мәңге балкысын дибез!



Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк Ленинградта сугышчан эш кайный башлый. Зур әһәмияткә ия объектларны, һәйкәлләрне каплыйлар, күп кенә завод-фабрикаларны, музей кыйммәтләрен илнең көнчыгышына озаталар. Сугыш башланып, бер атна үтүгә, ун эшелонда 235 мең бала шәһәрдән чыгарыла. Июль – август айларында эвакуацияләнгән халык саны 1 миллионга якынлаша. Шулай булса да, шәһәрдә 2,5 миллион кеше торып кала. Алар шәһәр оборонасын ныгыту эшләрендә катнаша: танкка каршы 625 километр озынлыгындагы чокыр, 400 километр эскарп, меңләгән дот һәм дзот, шәһәр эчендә 35 километр баррикада төзиләр. Июль башыннан Гитлер Ленинградны алу өчен 300 мең солдат һәм офицер, 600 орудие, 5000 миномет, 1000 танк, 1000 самолет җибәрә. Август азагында немецлар өлкәнең күп өлешен басып алалар һәм шәһәргә якынлашалар. Сентябрь башында Шлиссельбургны (хәзерге Петрокрепость) алып, ил белән бәйли торган коры җир юлларын кисәләр. Бердәнбер булып Ладога күле өстендәге су юлы гына кала. 1941 елның 4 сентябре көнне гитлерчылар Ленинградны артиллерия утына тоталар. Шул көннән 900 көнлек Ленинградны саклау эпопеясе башлана.

Ай буена барган каты сугышлардан соң, безнекеләр дошманнарның һөҗүмен туктаталар. Ленинградны ала алмагач, фашистлар шәһәр халкын ачтан үтерергә карар кылалар. 12 сентябрь мәгълүматлары буенча, шәһәрдә икмәк, ярма һәм ит - 30-35 көнгә, май - 45, шикәр 60 көнгә генә җитәрлек, ә ташкүмер, бик саклап тотканда да, ноябрьгә, сыек ягулык сентябрь ахырларына кадәр генә кулланырлык калган була. Ладога күлендә көзге навигация тукталгач, хәлләр тагын да кискенләшә. Башта ат олаулары (боз ныгып җитмәгән була), аннан автомашиналар белән ленинградлыларны азык-төлек, корал белән тәэмин итә башлыйлар. Бу юл тарихка “Яшәү юлы” дигән исем белән кереп кала. Ләкин алда — 29 ай, 900 көн... Тарихта бик күп шәһәр һәм крепостьларны саклау үрнәкләре булса да, 900 тәүлек буена каршы торып, җиңеп чыгуга ирешкән бер генә мисал да юк. Җир шарында җиңү өчен ул кадәрле кеше гомере бирелгән бер генә шәһәр дә юк. 1943 ел блокада боҗрасын өзгән ел булып тарихка кергән. 12 гыйнварда Ленинград һәм Волхов фронтлары, шәһәрнең көнчыгыш ягында (Ладога күле яклап) бергә кушылып, барлык көчләрен һөҗүмгә юнәлтәләр. 18 гыйнварда блокада чылбыры өзелә: ул 12 – 15 километр араны тәшкил итә.Дәүләт оборона комитеты азат ителгән җир буйлап тимер юл сузарга карар итә. Нева һәм Назия елгаларыннан ике күпер чыгасы 36 километр озынлыгындагы юлны 10 көн эчендә өлгертәләр. 7 февральдә яңа юлдан беренче поезд килә.Гитлерчыларның зур каршылык күрсәтүләренә карамастан, 1944 елның 14 гыйнварында гаскәрләр һөҗүмгә күчә. Канкойгыч сугышлар 15 көн буена бара. 27 гыйнварда безнең гаскәрләр 324 орудиедән салют биреп, Ленинградны азат иткән тарихи җиңү турында бөтен дөньяга хәбәр ирештерәләр. Блокадада калучылар арасында балалар да күп булган. Ләкин үлүчеләр аларның саны өлкәннәргә караганда азрак. Бу очраклы хәл түгел. Чөнки өлкәннәр үзләренә дә аз гына бирелгән икмәкнең дә күбесен сабый балаларына биргәннәр. Менә икмәкне өлкән буын кешеләре нигә бик кадерлиләр икән...

Сугыш инде күптән бетте. Окоплар җир белән тигезләнделәр, аларны яшел чирәм каплап китте, фронт юллары урынында яңа шәһәрләр һәм авыллар барлыкка килде, блиндажлар чәчәкләр белән капланды. Тик сугыш хатирәләре генә онытылмыйлар ...

27 нче гыйнвар көнне мәктәбебездә 5-8 сыйныфлар өчен Ленинград камалышы турында фильм күрсәтелде. Тетрәндергеч вакыйгалар, аянычлы язмышларны күреп, укучылар бу вакытларга кайткан кебек булдылар. Без, бүгенге көндә, бик рәхәт томышта яшибез. Бер-беребезне аңлап, авыр сүзләр әйтмичә, хөрмәт итеп яшик!

Илләрбез, көннәребез тыныч, имин булсын!

## “Халыклар дуслыгы” фестивале



3 нче февраль көнне мәктәбебездә халыклар дуслыгы фестивале узды. Һәр сыйныф бер милләт вәкилен тәкъдим итте. Киемнәрен киенеп, җыр-биюләрен һәм уеннарын күрсәтеп, аш-суларын әзрләп, милли ризыкларын тәкъдим иттеләр.

Әлеге фестиваль Халыклар бердәмлеге көненә карата икенче ел уза. Максаты: укучыларны җир шарында яшәүче барлык халыкларның гореф-гадәтләре белән таныштыру, дуслык-татулык тәрбияләү. Кичәдә 5-8, 10 нчы сыйныфлар катнашты.

Халыклар дуслыгына дан җырлый торган чын бәйрәм булды ул. Мәктәп балалары, ата-аналар, катнашында узган бу чарада татар, рус, чуваш, мордва җырлары, шигырьләр яңгырады, газеталар чыгарылды.

Милли киемнәргә киенеп, һәр милләт вәкилләре үзләренең милли ризыгын әзерләп алып килгән, һәрберсе үзләренә генә хас булган чәй эчү тәртипләрен күрсәтте. Самавырларның гына да ниндиләре генә юк иде анда, үзе бер тарихи экскурсия кебек булды.

## “Йолдызлы билет” бәйгесе

17 нче гыйнвар көнне “Йолдызлы билет” бәйгесенең мәктәп туры узды.Укучылар В.П.Аксенов, А.П.Чехов, В.М.Гаршин, Г.Х.Андерсен әсәрләрен укыдылар. Бу бәйгедә ата-аналар, укытучылар, укучылар да катнашып, көчләрен сыный ала иделәр. Бәйге бик җанлы, кызык узды.

## “Безнең белән бүлеш!”



31 нче гыйнвар көнне Татарстан буенча иң беренчеләрдән булып, мәктәбебездә “Безнең белән бүлеш!” дигән проект эшли башлады. Бездә кунакта президентыбыз Р.Н.Миннеханов, шәһәребез мэры Метшин И.Р., корпорациянең ген. директоры С.В.Чемезов булды. Мәктәбебездә фандомат-аппарат куелды. Ул 0,25 л. дан алып, 2,5 л. кадәрге пластик һәм алюмин шешәләрне кабул итәчәк.

## Тыл ветераннары белән очрашу

Аларны “Сугыш балалары” диләр. Әйтерсең аларны сугыш тудырган. Алар турында инде күп язылды, ләкин берәү дә башкаларның язмышын кабатламый. Бөек Ватан сугышында катнашкан, авыр тыл хезмәтен үз җилкәсендә татыган ветераннарыбызның саны елдан-ел кими бара. Шуңа күрә аларның исемнәрен оныту мөмкин түгел...

Гыйнвар аенда 5-8 нче сыйныфка кадәр укучылар тыл ветераннарына барып, сөйләшеп, аларның сугыш хатирәләрен яңарттылар...

Ул хатирәләр....Югалган бәхетле көннәр.....

## Сак булыгыз: грипп!!!



Грипп – вируслы тын юлы инфекциясе (ОРВИ) төркеменә керә. Ул эпидемиягә әверелүчән. Моннан тыш, ул организмга өзлегү дә китерергә мөмкин булган кискен авыру.

ОРВИ – киң таралган чир. Россиядә ел саен аның белән 27дән 40 миллионга кадәр кеше авырый. Аның вируслары селәгәй, сулыш алганда барлыкка килгән юешлек аша, сөйләшкәндә, елаганда, төчкергәндә, ютәллләгәндә тарала. Башкаларга ул шул ук һаваны сулаганда яки бер үк көнкүреш әйберләреннән файдаланганда күчә. Әлбәттә, халык аеруча җыелган җәмәгатьчелек урыннарында грипп эләктерү ихтималы аеруча зур.

Әлеге инфекция тиешенчә дәваланмаганда үпкә ялкынсынуы тудырырга мөмкин. Балаларда борын, колак авыруы туу, менингит башлану ихтималы да юк түгел. Грипп бигрәк тә сабыйлар һәм өлкән яшьтәгеләр, шулай ук ВИЧ-инфекциялеләр, каты авырулылар өчен куркыныч тудыра.

Авыруның гадәттәге сезонлы артуы февраль аенда көтелә. Бу авыру белән без беренче ел гына очрашмыйбыз һәм аны дәвалауга караганда кисәтүнең яхшырак булуын күпләр үз тәҗрибәләрендә сынап карады. Грипкка каршы прививка ясату – авырудан саклану өчен беренче адым.

Прививка ясалмаган алты айдан өч яшькә кадәр балалары булган әти-әниләр балалар поликлиникасындагы участок педиатрына, өлкәннәр район поликлиникасының прививка кабинетына мөрәҗәгать итә ала. Прививкалар бушлай ясала.

**Эпидемиягә ничек әзерләнергә, авыруны йоктырудан ничек сакланырга, ә инде авырып киткән очракта якыннарны ничек саклап калырга?**

Исегезгә төшерәбез, грипп калтырану, баш авыртуы, сөяк һәм мускуллар сызлау, хәлсезлек, температураның тиз күтәрелүе (39-40 градус) белән башлана. Авыр очракларда борыннан кан китү, косу, аң югалту кебек билгеләр булырга да мөмкин. Соңыннан коры ютәл башлана, томау төшә, тамак төбе кызарып чыга.

**Грипп симптомнары барлыкка килсә ни эшләргә?**

Өйдә калыгыз. Авыруны йоктырудан сакланыгыз.

Әти-әниләр! Авыру балаларны бакчага, мәктәпкә, массакүләм чараларга җибәрмәгез.

Тән температурасы 38-39 градустан артып китсә – табибка мөрәҗәгать итегез.

Гадәттәгедән күбрәк су эчегез (чәй, морс, компот, сок)

Йөткергәндә һәм төчкергәндә авыз һәм борынны салфетка яки кулъяулыгы белән капларга онытмагыз.

**Исегездә тотыгыз!**

- Грипны аяк өстендә үткәрергә ярамый;
- Вакытында табибка күренү һәм авыруны мөмкин кадәр иртәрәк дәвалый башлау (авырый башлаганнан соң беренче 48 сәгать) грипптан соң өзлегүне (бронхит, пневмония, отит, менингит) булдырмаячак.

Бүлмәне җиллләтергә онытмагыз. Салкын вакытта бүлмәне көненә 3-4 тапкыр 15-20 минут җиллләтегез. Грипп симптомнарын җиңеләйтү һәм авыруны профилактикалау максатыннан суган, сарымсак, бөтнек, лимон, гөлҗимеш, мүк җиләге, нарат җиләге, сырганак кебек дару үсемлекләрен кулланыгыз.

Грипп белән авыручыны аерым бүлмәдә урнаштыру кулай. Авыруның хәле начарлана башлау белән үк кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итегез.

Сәламәтлекне ныгыту

Чыныгу – кискен респиратор инфекцияләрне профилактикалауда аеруча зур әһәмияткә ия.

Күбрәк саф һавада йөрергә, бүлмәне ешрак җиллләтергә, көндәлек режимны үтәргә, дөрес тукланырга һәм температурага туры килерлек кием киярга кирәк. Аскорбин кислотасы (С витамины) организм өчен аеруча әһәмиятле. Ул организмның инфекциягә каршы тору-

Редакциянең адресы:420101, Казан шәһәре, Тулпар урамы, 2. Тел. 89050229576 Тираж – 50 экз.
Редколлегия:
Мәхмүтова Мәдинә, Мәхмүтова Мәликә, Хөснетдинова Камилия, Вәлиева Диләрә,Корчагина Яна, Хәсәнова Адилә, Мельникова Аделина
Җитәкчесе:А.Ф.Габдуллаҗанова